**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«27» 08 2020 ел Яр Чаллы № 3217

Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең «2016-2018 елларга Тукай муниципаль районында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культураны һәм спортны үстерү» программасын раслау хакында» 2015 елның 11 декабрендәге 3491 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 7 мартындагы 510-р номерлы күсәтмәсе һәм Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазландыру өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең «2016-2018 елларга Тукай муниципаль районында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культураны һәм спортны үстерү» программасын раслау хакында» 2015 елның 11 декабрендәге 3491 номерлы карарына (2018 елның 12 январендагы 71 номерлы, 2019 елның 18 декабрендәге 5491 номерлы, 2020 елның 3 июнендәге 2099 номерлы карарлар белән керетелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Тукай муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесендә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү хисабына 2020 елга финанслау күләмен 255 300,00 сум күләмендә арттырып үзгәрешләр кертергә.
2. «2016-2018 елларга Тукай муниципаль районында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культураны һәм спортны үстерү» программасы паспортының «Финанслау күләмнәре һәм чыганагы» бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп финанслау күләме | Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 2018-2020 елларда 4 922 886,36 сум тәшкил итә, шул исәптән: |

| | |
|---|---|
| | 2018 елда – 1 477 922,20 сум;<br>2019 елда – 1 531 023,16 сум;<br>2020 елда – 1 913 941,00 сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.<br>Республика, федераль бюджет акчалары һәм бюджеттан тыш чыганаклар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк. |

3. «2018-2020 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын гамәлгә ашыру буенча чараларның «Профилактик чаралар һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча чаралар» II бүлегенә «Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазландыру өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алу» пунктын өстәргә.

4. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә әлеге карарны 3 эш көне эчендә районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары И.Ш. Бариевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының
2020 елның 27.08
3217 номерлы карарына кушымта

**«2018-2020 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын гамәлгә ашыру буенча чаралар**

| № | Чаралар исеме | Финанс чараларын бүлү, еллар буенча (сумнарда) | | | | Финанслау чыганагы | Башкаручы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | Барлыгы | | |
| II. Профилактик чаралар һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча чаралар | | | | | | | |
| 1. | Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазландыру өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алу | | | 255300 | 255300 | Республика бюджеты | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ |